СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2025 елның 23 октябре № 2/6

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 14 ноябрендәге 39/7 номерлы карары (2020 елның 30 гыйнварындагы 42/5 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**4 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Һөнәри белем дәрәҗәсенә карата түбәндәге таләпләр билгеләнә:

1) авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш, вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен – югары белем булу;

2) авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарында вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен – югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

3) вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәрен биләү өчен – югары белем яки урта һөнәри белем булу.»;

**5 пунктны түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына түбәндәге таләпләр билгеләнә:

1) муниципаль хезмәтнең югары вазыйфаларын биләү өчен – кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

2) муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын биләү өчен – муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы»;

**9, 10 пунктларны** төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров